| «Рассмотрено» | «Согласовано» | «Утверждаю» |
| --- | --- | --- |
| Руководитель МО | Заместитель директора по УРВ ЧОУ «Академический Лицей им. Н.И. Лобачевского» | Директор ЧОУ «Академический Лицей им. Н.И. Лобачевского» |
| Хузина Р.Т. ______ | ______ Яковлева М.В. | ______ Беспалова Т.В. |
| Протокол № 1 | | Приказ № 43 |
| от «23» 08 2017 г. | от «23» 08 2017 г. | от «25» 08 2017 г. |

# РАБОЧАЯ ПРОГРАММА

учебного предмета, курса, дисциплины (модуля)
ЧОУ «Академический Лицей им. Н.И. Лобачевского»

Шакировой Гульнары Гасиховны, к.п.н.
Ф.И.О., категория

по татарской литературе, 6А класса
предмет, класс и т.п.

Рассмотрено на заседании
педагогического совета
протокол № 1
от «23» 08 2017 г.

20 17 - 20 18 учебный год

# УЧЕБНО-ТЕМАТИЧЕСКОЕ ПЛАНИРОВАНИЕ
# ПРАКТИЧЕСКОЙ ЧАСТИ УЧЕБНОЙ ПРОГРАММЫ
# ПО ТАТАРСКОЙ ЛИТЕРАТУРЕ

Класс: 6

Учитель: Шакирова Г.Р.

Количество часов: всего - 70 ; в неделю – 2.

Плановых контрольных работ: 1.

Административных контрольных работ: 1.

## Аңлатма язуы

Татар әдәбиятыннан 5, 6 һәм 7 нче сыйныф укучылары өчен төзелгән программа дәүләт стандартларының федераль компонентына, гомуми белем бирү федераль дәүләт стандартларына нигезләнеп эшләнгән Ә.Р.Мотыйгуллина, Р.Г.Ханнанов, Л.К.Хисматова, Э.Х.Гыйзәтуллина, Г.Г.Мулласалихова тарафыннан язылган дәреслекләрдән (1 нче, 2 нче кисәк) укытуны күздә тота. Программа стандартның эчтәлеген җентекләп ачып бирә, стандарт таләп иткән күләмдә рус телле балаларга татар әдәбиятын укытуның гомуми юнәлешләрен билгели, предмет чаралары белән укучыларны тәрбияләү юлларын, аларның әдәби үсеш дәрәҗәсен билгели.

Күпмилләтле аудиториядә татар әдәбиятын укыту өчен төзелгән программа бербөтен документ булып тора, ул биш өлешне иңли: аңлатма язуы; укыту курсының эчтәлеге, укыту-тематик планы; укучыларның әзерлек дәрәҗәсенә таләпләр; курсның укыту-методик тәэмин ителеше өчен әдәбият исемлеге.

Әдәбият һәр яктан үскән, рухи яктан бай, әхлакый идеаллары һәм эстетик таләпләре булган камил шәхес тәрбияләү әһәмиятле урын алып тора. Урта белем бирү системасындагы татар әдәбияты курсы сәнгатьне тормыш белән бәйләп өйрәнүгә, эчтәлек белән форма берлеге, тарихилык, традиция һәм новаторлык, тарихи-культурологик мәгълүматларны аңлау, әхлакый-эстетик күзаллау булдыру, әдәбият теориясе һәм тарихы буенча төшенчәне үзләштерү, әдәби әсәрне бәяләү һәм күнекмәләрне формалаштыру, әдәби телнең сәнгатьлелек чараларын үзләштерү.

Федераль дәүләт стандартларына нигезләнеп төзелгән татар әдәбияты дәреслекләре барлык фәннәрне өйрәнү барышындагы фундаменталь төшкә (фундаментальное ядрога), универсаль уку гамәлләренә нигезләнә, укучыларның яшь һәм әдәби үсеш дәрәҗәсен исәпкә ала. Укыту һәм тәрбиянең гомуми нәтиҗәләре иҗтимагый, шәхси, танып-белү һәм коммуникатив үсешне тәэмин итеп, укучыларның белемнәрен, күнекмәләрен үстереп, дөньяны танып белүгә әзерләп, хезмәттәшлеккә, үзлегеннән белем алуга, камиллеккә омтылучы шәхес тәрбияләүгә барып тоташа. Аерым алганда, уку-укытуга системалы-гамәли якын килү нәтиҗәсендә, укучыларның **иҗтимагый** үсешенә (халыкның рухи кыйммәтләрен аңлаучы, үстерүче Россия гражданины тәрбияләү); **шәхси** үсешенә (үзлегеннән белем алырга, иҗади сәләте үскән, компетентлы, үзаңы үскән, үзенең гражданлык карашларын ачыктан-ачык белдерүгә сәләтле, үз-үзенә тәнкыйди караштa торган, тормыш авырлыкларын каршы торырлык шәхес тәрбияләү); **танып белү** эшчәнлеген үстерүгә

(фәнни дөнья сурәтен аңлаучы, үзенең танып-белү һәм интеллектуаль эшчәнлеге белән идарә итә ала торган, уку, белем алу чараларын күзаллый торган, репрезентатив, символик, логик, иҗади фикерләү сәләте үскән, рефлексиягә сәләтле укучы тәрбияләү); **коммуникатив** үсешкә (аралашу компетенциясе үскән, тыңларга, диалогта, гомуми сөйләшүдә катнаша алырлык, туган телен, рус телен, чит телне камил белүенә) басым ясалды. Шул ук гамәлләрне тормышка ашыру барышында, яшүсмерләрнең яшь үзенчәлекләре дә игътибарга алынды.

Күпмилләтле мохиттә гомуми әдәби белем бирү барышында универсаль уку гамәлләре дүрт блокка бүлеп каралды. Алар арасында **шәхси** УУГ − тормышчан, шәхескә юнәлтелгән, һөнәри юнәлештә үз юлын табуга, кешенең эчке потенциалын рациональ файдалана белүенә бәйле блок. Р**егулятив** уку гамәлләре шәхес тәрбияләүдә планлаштырырга өйрәтү, фаразлау, коррекция, бәяләү кебек якларны үзәккә ала. **Танып белү** гамәлен алгы планга чыгарган блокта логик, проблеманы кую һәм чишүгә юнәлтелгән, тамга-символик якны иңләгән гомумуку гамәлләренә игътибар ителә. **Коммуникатив** УУГ кешеләр язмышына битараф булмауны, кешеләргә ярдәмчеллек сыйфатларын тәрбияләүне, иҗтимагый компетентлыкны үз эченә ала.

Универсаль уку гамәлләрен рус телле балаларга татар әдәбиятын укыту барышында куллану нәтиҗәсендә, укучыларны мөстәкыйль эшләргә өйрәтү юнәлеше көчәйде (мәсәлән: өй эше бирү − берничә вариантта). Бу вакытта укытучы эшчәнлегендә идарә итү алымнары көчәя.

Шул рәвешле, федераль дәүләт стандартларына таянып татар әдәбиятын өйрәнүнең **максаты** да ачыкланды: туган халкының һәм җирле халыкның телен, мәдәниятен, әдәбиятын яхшы белгән, һәрьяктан камил, милли горурлык хисләре үскән шәхес (гражданин) тәрбияләү.

Әлеге максатны тормышка ашыру өчен, түбәндәге **бурычлар** билгеләнде:

− Татарстан төбәгендә яшәп, җирле халык белән аралашкан укучыларны төбәкнең әдәби-мәдәни байлыгы белән якыннан таныштыру;

− татар әдәбияты турындагы мәгълүматларны төрле халык фольклоры, әдәбияты, мәдәнияте, милли образлары белән чагыштырма-типологик аспектта бирү;

− татар халык авыз иҗаты турында тулы күзаллау булдыру, аны баланың үз туган халыкының рухи җәүһәрләре белән чагыштырырга күнектерү;

− татар әдипләре, мәдәният әһелләре турында күзаллау булдыру, аларны таныргa, аңларга, башка халык сүз сәнгатен үстерүчеләр белән чагыштырма планда бәяләргә өйрәтү;

− татар, рус, Россиядә яшәүче башка халыклар, бөтендөнья әдәбияты белеме казанышларының уртак нигезен аңлау, аларны үстерү һәм киңәйтү.

Әлеге максат һәм бурычларга ирешү өчен, түбәндәге принциплар истә тотылырга тиеш. Рус телендә сөйләшүче балалар өчен татар әдәбиятының асылын төшендерү укытучының сүз сәнгате серләрен яхшы белүен, иҗади эшләү күнекмәләре булуын таләп итә. Мәктәп баласына сүз сәнгатенең серләрен ачуда **эстетик принцип** (укытучының матурлыкны күрә алуы һәм башкаларне да күрергә өйрәтә алуы), **эзлеклелек** (укучы алган белемнең тулыланып, баеп баруы), **әдәбиятны сүз сәнгате буларак өйрәнү** (татар телендә язылган әсәрләрдә әдәби образларны ачу үзенчәлекләре, татар теленең матурлыгын күрергә өйрәтү), күләме ягыннан кечкенә булган әсәрләргә шәхси мөнәсәбәт булдыру, ягъни **психологик принцип** (мәктәп баласының яшь үзенчәлекләрен, әдәби әзерлек дәрәҗәсен исәпкә алып эш итү) ярдәмгә килә. Аерым игътибар **коммуникативлык принцибына** бирелә. Бу принципның өстен чыгуы рус телендә сөйләшүче укучыларның әдәби әсәр аша татар теленең серләренә тирәнрәк төшенүләре, матур әдәбият әсәрен сорауларга нигезләнеп сөйли алуы, үз фикерләрен ачык әйтә алуы, әдәби әсәрнең аралашу чарасына әверелүе белән дә бәйле. Укучыларның әдәби әсәрне кабул итү һәм әдәби үсеш үзенчәлекләрен исәпкә алып, **дифференциацияләү** (аерым төркемнәргә аерып, бүлеп эшләү) һәм **интеграцияләү** (татар теле һәм рус әдәбияты дәресләрендә алынган теоретик белемнәрне һәм гамәли эш күнекмәләрен файдалану) дә үзәккә алына.

# календар-тематик план

| № | Дәрес темасы | Төп эчтәлек | Көтелгән нәтиҗә | | | Укучылар эшчәнлеге төрләре | Үткәрү вакыты план / факт | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | метапредмет | Предмет | шәхескә кагылышлы | | | |
| 1-2 | Халык авыз иҗаты үрнәкләре | Халык зур ул, әдип ул, шагыйрь ул | Төрле халыкларның фольклор үрнәкләрен чагыштырып карау | Халык авыз иҗатын гомуми күзаллау | Халык авыз иҗаты әсәрләренә карата кызыксыну уяту, сөйләмне алар ярдәмендә баету мөмкинлеген аңлау | "Халык авыз иҗаты" схемасы белән эш, дәреслек, эш дәфтәрендә биремнәр, рус халык авыз иҗаты белән чагыштыру | 4.09-9.09<br>4.09-9.09 | |
| 3-4 | Һич сине куркытмасыннар Шүрәле, җен һәм убыр | "Шүрәле", "Су анасы", "Албасты" халык мифлары | Рус, грек, татар мифологиясен чагыштырып белү | Мифик геройлар турында төшенчә формалаштыру, миф белән әкиятнең аермасын аңлату | Иптәшең белән сөйләшә, башкаларны тыңлый белү – аралашу кулҗтурасы тәрбияләү. | Парлап, төркемләп сөйләшү, ишетеп аңлау, рольләргә бүлеп уку, сәнгатьле уку | 11.09-16.09<br>11.09-16.09 | |
| 5-6 | Әйтем – сүзнең бизәге, мәкаль – сүзнең җиләге | Мәкальләр һәм әйтемнәр | Татар һәм рус мәкальләрен чагыштыру | Мәкаль һәм әйтем турында теорияне аңлап истә калдыру, аларның аермасын белү | Халык авыз иҗаты белән кызыксыну уяту, әдәплелек тәрбияләү | Төркемнәрнең чыгыш ясавы, теоретик материал белән танышу, дәреслек, дәфтәр белән эш | 18.09-23.09<br>18.09-23.09 | |
| 7-8 | Халык җырлары – иң кадерле мирас | Халык авыз иҗатында җыр жанры, йола, уен, тарих җырлар | Халкыбызның онытылып бара торган бәйрәмнәре белән таныштыру | Халык җырлары жанрлары, йола җырлары турында белешмә бирү | Укучыларда халкыбызның йолалары, гореф-гадәтләренә мәхәббәт тәрбияләү | "Халык авыз иҗаты" схемасы белән эш, ишетеп аңлау, дәреслек, дәфтәр беллән эш, парлап сөйләшү | 25.09-30.09<br>25.09-30.09 | |
| 9-10 | Шигърияттә - халык көе | Г. Тукайның "Туган тел", "Туган авыл" | Милли үзаңны үстерү, | Г.Тукайның халык җырлары турындагы | Тукайга хөрмәт, милләтеңә, җиреңә, туган телеңә, мәхәббәт тәрбияләү | Бер уен  җырын яттан сөйләү, тыңлап аңлау, сәнгатьле уку, | 2.10-7.10<br>2.10-7.10 | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | шигырьләре, А. Монасыйпов иҗаты | үткәнеңне, тарихны өйрәнү | хезмәтләре белән танышу, “Туган тел, “Туган авыл” җырларын өйрәнү | | аудиоязма тыңлау, дәфтәрдә эш, презентация карау | | |
| 11-12 | Татарстан Республикасының Дәүләт гимны | Татарстан Республикасының Дәүләт гимны | Дәүләт гимнын тыңлау тәртибен белү | Дәүләт гимны турында теоретик төшенчә бирү һәм гимның сүзләрен аңлап истә калдыру | Татарстан Республикасы, аның казанышлары белән горурлану хисләре тәрбияләү | Фронталь әңгәмә, яңа сүзләр белән танышу, җыр тыңлау, җыр сүзләрен тәрҗемә итү, истә калдыру | 9.10-14.10<br>9.10-14.10 | |
| 13-14 | Халык язучысы Н.Исәнбәтнең тормыш юлы, иҗаты | Н.Исәнбәтнең «Өч матур сүз» шигыре, «лирик герой» төшенчәсе. | Автор әйтергә теләгән төп фикерне таба, аны тормыш белән бәйли белү. | Язучы Н.Исәнбәт иҗаты белән танышу, «Өч матур сүз» шигыренең эчтәлеген, «лирик герой» төшенчәсен аңлау. | Әти-әнинең, туган илнең кадере турында аңлау, сөйләм телен үстерү. | Фронталь әңгәмә, язучы турында презентация ясау, карау, шигырьне тыңлап аңлау, сәнгатьле уку, рольләргә бүлеп уку, дәреслек, дәфтәр белән эш. | 16.10-21.10<br>16.10-21.10 | |
| 15-16 | М.Гафури тормыш юлы һәм иҗат биографиясе | М.Гафури иҗаты, «Әтәч белән Сандугач» мәсәле, «сынландыру», «мәсәл». “Ана” шигыре | Татар мәсәлчеләрен рус әдәбиятын-дагы мәсәлчеләр белән чагыштыра, мөстәкыйль укып, нәтиҗә ясый белү. | Язучы М.Гафури иҗаты, «Әтәч белән Сандугач» мәсәле белән танышу, «сынландыру» төшенчәсен аңлау. | Тормышта ихтыяр көченең, белемнең кирәклеген аңлау. | Биографияне мөстәкыйль укып, сорауларга җавап эзләү, сәнгатьле уку, сайлап уку, яңа сүзләрне өйрәнү, мәсәлнең моралең табу, рәсемнәр белән эш, дәреслек, дәфтәр белән эш. | 23.10-28.10<br>23.10-28.10 | |
| 17-18-19 | Барыбызга да таныш Шүрәле. Г.Тукай иҗаты | Г.Тукай иҗаты, «Шүрәле» әкият-поэмасы. | «Аршын» сүзе-нең мәгънәсен аңлау, кайда | Шагыйрь Г.Тукай биографиясен истә калдыру, «Шүрәле» әкият- | Экологик тәрбия бирү. | Дәреслек, дәфтәр белән эш, яңа сүзләрне активлаштыру — сүзләр, җөмләләр төзү, | 6.11-11.11<br>6.11- | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | кулланылы-шы турында белү, рәссам Б.Әлменов картинасы белән танышу. | поэмасының 2, 3 нче өлешләре белән таныш булу. | | рольләргә бүлеп уку, сайлап уку, мультфильм карау. | 11.11<br>13.11-18.11 | |
| 20-21 | Дөнья-ларны «гизгән» Шүрәле. “Шүрәле” балеты | Ф.Яруллин-ның «Шүрәле» балеты. **Контроль эш.** | «Балет», «либретто», «балетмейстер» төшенчәләрен белү. | Г.Тукайның «Шүрәле» әкият-поэмасына балет язылуы, аның эчтәлеген белү, композитор Ф.Яруллин турында мәгълүматлы булу. | Эстетик тәрбия бирү. | Теоретик төшенчәләр белән танышу, видеоязма карау, композитор биографиясе белән танышу, аның буенча хронологик таблица тутыру, фикер алышу. | 13.11-18.11 | |
| 22-23-24 | М.Җәлили – герой шагыйрь | М.Җәлил иҗаты, «Чәчәкләр», «Тик булса иде ирек» шигырь-ләре. | Тарихтан сугыш чоры турында белү. | М.Җәлил биографиясен искә төшерү, сугыш чоры иҗаты белән танышу, «Чәчәкләр» шигырен аңлап уку, «символ», «строфа» төшенчәләре белән танышу. | Туган илне ярату, туган илне саклау — мактаулы икәнен аңлау. | Дәреслек, дәфтәр белән эш, парлап сөйләшү, шигырьне тыңлап аңлау, ярымтавыш белән уку, чылбыр буенча сәнгатьле уку, эчтәлек буенча фикер алышу, шигырьгә анализ ясау. | 20.11-25.11<br>20.11-25.11<br>27.11-2.12 | |
| 25-26-27 | Ә.Еники иҗаты. “Туган туфрак”хикәясе<br>Бүлекне кабатлау | Ә.Еники иҗаты, «Туган туфрак» хикәясе. Тест. | Катлаулы текст белән эшләү, иң әһәмиятле-сен таба белергә өйрәнү. | Ә.Еники иҗаты белән танышу, «Туган туфрак» әсәрен укый башлау. | Өлкән буынга карата ихтирам, туган җиргә мәхәббәт тәрбияләү. | Презентация ярдәмендә язучы тормышы белән танышу, төркемнәрдә фикер алышу, ишетеп аңлау, сүзлекчә белән эш, укыганны тәрҗемә итү, сораулар, биремнәр үтәү, таблица тутыру. | 27.11-2.12<br>4.12-9.12<br>4.12-9.12 | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 28-29-30 | Г.Ибраһимов иҗаты. “Карлар ява” хикәясе | Г.Ибраһимов иҗаты, «Кар ява» хикәясе. | Табигатькә карата күзәтүчәнлек тәрбияләү, һава торышының үзгәрешен аңлау. | Г.Ибраһимовның тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә бирү, «Кар ява» әсәрен өйрәнү, һава торышы турында сөйли белү. | Укучыларга экологик тәрбия бирү. | Портретлары буенча язучыларны тану, яңа сүзләрне истә калдыру, язучы биографиясен уку, сораулар төзү, җавап бирү, презентация карау, караган буенча фикер алышу, һава торышы турында сөйләү. | 11.12-16.12<br><br>11.12-16.12<br>18.12-23.12 | |
| 31-32 | Татар шагыйрьләрендә Кыш образы | К.Нәҗми, Л.Шагыйрьҗан, М.Фәйзуллина, Р.Вәлиева иҗатлары | Игътибарны арттыру, балаларда күзәтүчәнлек тәрбияләү. | Язучыларның иҗаты турында белү, «Кызыклы хәл» шигырен өйрәнү, сөйләм телен үстерү. | Укучыларга экологик тәрбия бирү. | Язучылар тормышы белән танышу, презентация карау, кош исемнәрен истә калдыру, дәреслек, дәфтәр белән эш, парларда сөйләшү. | 18.12-23.12<br><br>25.12-30.12 | |
| 33-34 | Т.Миңнуллин – драматург. “Акбай һәм Кыш бабай” пьесасы | Т.Миңнуллин иҗаты, «Акбай һәм Кыш бабай» пьесасы. | Укучыларда татарча җыр-бию, рольләргә бүлеп уку сәнгатен үстерү. | Т. Миңнуллинның тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә бирү, «Акбай һәм Кыш бабай» әсәрен өйрәнү. | Җыр, бию сәнгатенә кызыксыну тудыру. | Сорауларга җавап эзләү, ишетеп аңлау, рольләргә бүлеп уку, әсәрдә автор әйтергә теләгән фикерне табу, әдәби әсәр турында фикер алышу. | 25.12-30.12<br><br>8.01-13.01 | |
| 35-36-37 | Күп укыган-күп белер. К.Насыйри иҗаты | К. Насыйриның «Әбүгалисина» әсәре. К.Насыйри музейлары | Үзеңә кирәкле белемне дөрес итеп таба белергә, китапларны теләп укырга | К.Насыйриның тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә бирү, «Әбүгалисина» әсәрен өйрәнү. | Белемгә омтылыш тәрбияләү. | Презентация ярдәмендә язучы тормышы белән танышу, төркемнәрдә фикер алышу, ишетеп аңлау, сүзлекчә белән эш, укыганны тәрҗемә итү, сораулар, биремнәр үтәү, | 8.01-13.01<br><br>15.01-20.01<br><br>15.01-20.01 | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | күнектерү. | | | таблица тутыру. | | |
| 38-39 | Тырышкан табар-ташка кадак кагар. Г.Сабитов иҗаты | Г.Сабитов иҗаты, «Чүкеч» хикәясе, «хикәяләү» төшенчәсе. | Хикәядә очрый торган яңа сүзләрне (эш кораллары атамаларын) тормыш белән бәйләп истә калдыру. | Г.Сабитов турында белешмә бирү, «Чүкеч» хикәясен өйрәнү, «хикәяләү» төшенчәсе белән танышу. | Хезмәт тәрбиясе бирү, җаваплылык хисләре, һәр эшне ахырына кадәр җиткерә белү теләге тәрбияләү. | Язучы тормышы белән танышу, презентация карау, инструмент исемнәрен истә калдыру, дәреслек, дәфтәр белән эш, парларда сөйләшү. | 22.01-27.01<br><br>22.01-27.01 | |
| 40-41-42 | Әдәбият теориясе: хикәяләүче төшенчәсе А.Алиш иҗаты | А.Алиш иҗаты, «Әни ялга киткәч» хикәясе, «хикәяләү-че» төшен-чәсе. **Контроль эш.** | Төрле ситуациядә югалып калмас-ка кирәклеген аңлату. | А.Алиш турында белешмә бирү, «Әни ялга киткәч» хикәясен өйрәнү, «хикәяләүче» теоретик төшенчәсен истә калдыру. | Укучыларга хезмәт тәрбиясе бирү. | Дәреслек, дәфтәр белән эш, парлап сөйләшү, яңа сүзләрне төрле фигыль формаларына кую, җөмләләр төзү, план төзү, укыганны гади җөмләләр белән кыскача сөйли белү. | 29.01-3.02<br><br>29.01-3.02 | |
| 43-44-45 | Ф.Яруллин тормыш юлы һәм иҗаты | Ф.Яруллин иҗаты, «Кояштагы тап» хикәясе, «притча» төшенчәсе “Тугры дус” шигыре | Җаваплылык хисләре, һәр эшне ахырына кадәр җиткерә белү теләге тәрбияләү. | Ф.Яруллин турында белешмә бирү, «Кояштагы тап» хикәясен уку, «притча» төшенчәсен истә калдыру. | Әниләргә карата шәфкать-лелек, хөрмәт хисләрен үстерү. | Презентация ярдәмендә язучы тормышы белән танышу, төркемнәрдә фикер алышу, ишетеп аңлау, сүзлекчә белән эш, укыганны тәрҗемә итү, сораулар, биремнәр үтәү, хронологик таблица тутыру, план төзү. | 5.02-10.02<br><br>5.02-10.02<br><br>12.02-17.02 | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 46-47 | Иң элек син Кеше бул, балам! Г.Зәйнәшева – татар шагыйрәсе | Г.Зәйнашева иҗаты, «Кем булырга» шигыре. М.Латыйфуллинның “Сәйдәшнең юл башы” хикәясе | Төрле һөнәрләр, аларның үзенчәлекләре турында мәгълүмат бирү. | Г.Зәйнашева турында белешмә бирү, «Кем булырга?» шигырен өйрәнү. М.Латыйфуллинның «Сәйдәшнең юл башы» өзеген уку, «биографик әсәр» төшенчәсе белән танышу. | Тормышта үз урыныңны, һөнәреңне, аңа ирешү юлларын табарга омтылыш тәрбияләү. | Шагыйрәнең тормыш юлы белән танышып, хронологик таблица тутыру, шигырьне тыңлау, ярымтавыш белән уку, чылбыр буенча уку, сайлап уку, яңа сүзләрне өйрәнү, парлап сөйләшү, бер һөнәр турында сөйләү. | 12.02-17.02<br>19.02-24.02 | |
| 48-49 | С. Сәйдәшев – татар композиторы | С.Сәйдәшев иҗаты. | Җыр, музыка сәнгатенә мәхәббәт тәрбияләү. | С.Сәйдәшевның тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә бирү. | Төбәгебезнең күренекле шәхесләре белән горурлану хисләре уяту. | Презентация карау, композитор турында музыка дәресендә алган белемнәрне яңа мәгълүмат белән тәңгәлләштерү, дәреслек, дәфтәр белән эш, музыка тыңлау, фикер алышу, парлап сөйләшү. | 19.02-24.02<br>26.02-3.03 | |
| 50-51 | Р.Фәйзуллин тормыш юлы һәм иҗаты Бүлекне йомгаклау | Р.Фәйзуллин иҗаты, «Бердән-бер» шигыре. Тест. | Төрле яклап үз сәләтләрен үстерүгә омтылыш тәрбияләү. | Р.Фәйзуллин турында белешмә бирү, «Бердәнбер» шигырен уку, анализлау. | Әти-әни, туган ил алдында җаваплылык хисләре, ватанпәрвәрлек тәрбияләү. | Язучы иҗаты белән танышу, шигырьне тыңлап аңлау, чылбыр буенча сәнгатьле уку, сайлап уку, дәреслек, дәфтәр белән эш, төркемнәрдә фикер алышу. | 26.02-3.03<br>12.03-17.03 | |
| 52-53 | Туган туганга кирәк. Дәрдемәндә иҗаты | Дәрдемәнд иҗаты, «Ике туган» әсәре. | Сәламәт яшәү рәвеше турында мәгълүмат бирү. | Дәрдемәнднең тормыш юлы белән танышу, әсәрне уку. | Әхлак тәрбиясе бирү, сәламәт яшәү рәвеше турында мәгълүмат бирү. | Презентация ярдәмендә язучы тормышы белән танышу, төркемнәрдә фикер алышу, ишетеп аңлау, сүзлекчә белән | 12.03-17.03 | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | эш, укыганны тәрҗемә итү, сораулар, биремнәр үтәү, хронологик таблица тутыру. | | |
| 54-55 | Шагыйрь үткән юл. Һ.Такташ иҗаты | Һ.Такташ иҗаты, «Мокамай» поэмасы. | Тарихтан Һ.Такташ яшәгән чор турында мәгълүмат бирү. | Һ.Такташ турында мәгълүмат бирү, «Мокамай» поэмасы белән таныша башлау. | Туган якның кадерле, онытылмас икәнен аңлату. | Презентация ярдәмендә шагыйрь тормышы, ул яшәгән чор белән танышу, төркемнәрдә фикер алышу, ишетеп аңлау, сүзлекчә белән эш, укыганны тәрҗемә итү, сораулар, биремнәр үтәү, сәнгатьле уку. | 19.03-24.03<br><br>19.03-24.03 | |
| 56-57 | Р.Харисның тормыш юлы һәм иҗаты. “Серле алан” пьесасы | Р.Харис иҗаты, «Серле алан» пьесасы, «диалог», «монолог», «символик образ» төшенчәләре. | Укыганны гомумиләштерә, нәтиҗә ясый, иң мөһим мәгълүматны аерып ала белү. | Р.Харис иҗаты белән танышу, пьесаны укып, нәтиҗә ясау, «диалог», «монолог» төшенчәләрен әдәби термин буларак истә калдыру. | Үзләре өчен, әйләнә-тирә өчен җаваплылык хисләре тәрбияләү. | Ишетеп аңлау, рольләргә бүлеп уку, әсәрдә автор әйтергә теләгән фикерне табу, әдәби әсәр турында фикер алышу, Р.Харисның рәсемнәре буенча җөмләләр төзү. | 2.04-7.04<br><br>2.04-7.04 | |
| 58-59 | Татар балалар шагыйрьләре – Э.Шәрифуллина, ш.Галиев иҗатлары | Э.Шәрифуллина, Ш.Галиев иҗаты, «Дуслык, чын дуслык» шигыре. | Шигъри әсәрне җиңел истә калдыру ысулларын өйрәнү. | Э.Шәрифуллина, Ш.Галиев иҗаты турында мәгълүмат бирү, дуслык турында шигырьне уку, сөйләм телен үстерү. | Дуслыкның кеше өчен мөһимлеген аңлату.<br>Ш.Галиев – юмор остасы | Шагыйрә турында белешмәне уку, сораулар төзү, сорауларга җавап бирү, шигырьне тыңлау, тәрҗемә итү, сәнгатьле уку, сайлап уку, биремнәр үтәү, ятлау. | 9.04-14.09<br><br>9.04-14.09 | |
| 60-61 | Ике тиен — зур акчамы? Ф. Шәфигуллин иҗаты | Ф.Шәфигуллин иҗаты, «Ике тиен акча», “Акбай белән Карабай” | Укылган әсәрне бүгенге көн, көндәлек тормыш белән | Ф.Шәфигуллин тормышы, иҗаты белән танышу, юмор аша язучы әйтергә теләгән фикерне табу. | Әхлак тәрбиясе бирү. | Дәреслек, дәфтәр белән эш, парлап сөйләшү, яңа сүзләрне төрле фигыль формаларына кую, җөмләләр төзү. | 16.04-21.04<br><br>16.04-21.04 | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | хикәяләре | бәйләнештә күзаллый белү. | | | | | |
| 62-63 | Татар юмор осталары | В.Радловның “Шаян кеше”, Григорий Остерның “Серне ачты”, Н.Мадьяровның “Урман аланына баргач” хикәяләре | Галим В.Радлов, Григорий Остер, Нәҗип Мадьяров турында мәгълүмат бирү. | Хикәяне уку, сөйләм телен үстерү. | Күп телләр белергә омтылыш, чит телләргә ихтирам тәрбияләү. | Язучылар тормышы белән танышу, төркемнәрдә фикер алышу, ишетеп аңлау, сүзлекчә белән эш, укыганны тәрҗемә итү, сораулар, биремнәр үтәү, эчтәлекне берничә җөмлә белән сөйләү. | 23.04-28.04<br>23.04-28.04 | |
| 64-65-66 | Р.Әхмәтҗанов, Г.Рәхим иҗатлары | Р.Әхмәтҗа-новның «Иртә әле...» шигыре, «пейзаж» төшенчәсе. Г.Рәхимнең “Апрель” хикәясе | Рәсем сәнгатендә пейзаж белән әдәбияттагы «пейзаж» төшенчәсен бәйләнештә күзаллау. | Р.Әхмәтҗанов, Г.Рәхим турында мәгълүмат, «Иртә әле...» шигырен укып аңлау, «пейзаж» төшенчәсен белү. | Табигатьнең матурлыгын күрергә өйрәтү, экологик тәрбия бирү. | Шагыйрьләрнең тормыш юлы белән танышып, хронологик таблица тутыру, шигырьне тыңлау, ярымтавыш белән уку, чылбыр буенча уку, сайлап уку, яңа сүзләрне өйрәнү, парлап сөйләшү. | 30.04-5.05<br>30.04-5.05<br>7.05-12.05 | |
| 67-68 | Көтеп алган Сабантуй Г.Бәшировның “Туган ягым – яшел бишек” хикәясе | Г.Бәширов-ның «Язгы сабан туйлары» әсәре. | Төрле бәйрәмнәр-нең (бу очракта Сабантуй мисалында) тарихы белән кызыксыну. | Г.Бәширов турында белү, «Язгы сабан туйлары» өзеген укып аңлау, сөйләм телен үстерү. | Халыкның гореф-гадәтләре, йолаларына ихтирам тәрбияләү. | Яңа сүзләрне язу, эчтәлек буенча төркемнәрдә фикер алышу, әсәргә җиңелчә әдәби анализ ясау, сораулар һәм биремнәр, әсәрне өлешләргә бүлү, план төзү, план буенча гади җөмләләр белән сөйләү. | 7.05-12.05<br>14.05-19.05 | |
| 69-70 | Татар шагыйрьләрен | Б.Рәхмәт “ Сабан туенда”, | Рәсем сәнгате | Рәссам Л.Фәттахов, аның картинасы | Халыкның гореф-гадәтләре, йолаларына ихтирам тәрбияләү. | Рәссам турында уку, презентация карау, | 14.05-19.05 | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | дә, рәссамнарында Сабан-туй темасы. Үткәннәргә йомгак ясау | Г.Морат “Сабан туе”, Л.Фәттахов «Сабантуй» картинасы. Проект. | белән әдәбиятның бәйләнеше. | турында белү, сөйләм телен үстерү. | | картинаны карау, фикер алышу, сораулар төзү, сорауларга җавап бирү, картинаны сурәтләп сөйләү, парлап сөйләшү. | 21.05-26.05 | |